**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 21 марты №33-108

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 05.09.2022 №26-83 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 05.09.2022 елның 26-83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә (01.11.2022 елның 28-90 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 3 статьяның 1 өлеше түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт белән тулыландырылырга:
«13) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының барлык утырышларында алты ай рәттән депутат булмау.»;

1.2. 3 статьяның 3 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Раиса)» сүзләре белән алыштырырга.

1.3. 18 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктының б пунктында "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен»Татарстан Республикасы башлыгы (Раиса) " сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә: http//pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә: http// novosheshminsk.tatarstan.ru/. бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияләрне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай
авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов